КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 10 сентябрь г.Казань № 976

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына грант ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 14 июль, 572 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Агросәнәгать комплексына грант ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 14 июль, 572 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 октябрь, 1013 нче; 2022 ел, 11 май, 428 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Агросәнәгать комплексы өлкәсендә фәнни тикшеренүләргә һәм эшләнмәләргә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен бюджет учреждениеләренә һәм автоном учреждениеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан грантлар бирү тәртибендә:

4.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9. Конкурс комиссиясе заявкалы конвертларны һәм үзгәрешләр кертелгән заявкалы конвертларны ачуны гамәлгә ашыра һәм заявкалар кабул итү тәмамланган көннән 14 эш көне эчендә:

заявкаларны һәм сайлап алуга тапшырылган документларны аларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен билгеләү өчен карап тикшерә;

бу Тәртип кушымтасында күрсәтелгән сайлап алу критерийлары нигезендә заявкаларны бәяләүне башкара. Баллар Министрлык тарафыннан расланган форма буенча бәяләү кәгазенә кертелә. Һәр бәяләү кәгазе буенча сайлап алуда катнашучының баллар суммасы буларак билгеләнә торган йомгаклау баллы чыгарыла;

заявкалардагы мәгълүматка һәм заявка бирүченең бирелә торган сорауларга җавапларына, заявканы һәм сайлап алуга тапшырылган документларны бәяләү өчен

бу Тәртип кушымтасында күрсәтелгән критерийларга нигезләнеп, кара-каршы әңгәмә барышында һәр заявка буенча карар кабул итә һәм балларны Министрлык тарафыннан расланган форма буенча бәяләү кәгазенә кертә. Һәр бәяләү кәгазендә сайлап алуда катнашучының баллар суммасы буларак билгеләнә торган йомгаклау баллы чыгарыла;

әгәр баллар суммасы дүртән күбрәк булса, һәр заявка буенча заявканың бу Тәртип кушымтасында күрсәтелгән сайлап алу критерийларына туры килүе турында уңай карар кабул итә,

әгәр баллар суммасы дүрттән азрак булса, заявканың бу Тәртип кушымтасында күрсәтелгән сайлап алу критерийларына туры килмәве турында карар кабул итә.

Иң күп баллар җыйган сайлап алуда катнашучы җиңүче дип таныла. Җиңүчеләр дип танылган сайлап алуда катнашучылар саны билгеләнгән тәртиптә Министрлыкка җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә билгеләнә.

Конкурс комиссиясе утырышының беркетмәсе аның рәисе тарафыннан утырыш үткәрелгән көннән биш көн эчендә раслана. Конкурс комиссиясе утырышының беркетмәсе расланганнан соң, Министрлык биш эш көне эчендә грант бирү турында карар кабул итә һәм сайлап алуда җиңүчеләр турында боерык чыгара.

Әгәр сайлап алуда катнашу өчен бер заявка да бирелмәгән булса, конкурс комиссиясе беркетмәдә бирелгән заявкалар булмау фактын чагылдыра.

Әгәр сайлап алуда барлык катнашучыларның заявкалары кабул ителмәгән булса, конкурс комиссиясе беркетмәдә заявкалар кабул ителмәү фактын чагылдыра.

Баллар тигез булган очракта, өстенлек иң алдан кергән заявкага бирелә.

Әгәр, бер заявкадан башка, сайлап алуда барлык катнашучыларның заявкалары кабул ителмәгән булса, конкурс комиссиясе беркетмәдә сайлап алуда бердәнбер җиңүчене тану фактын чагылдыра.»;

әлеге карар белән расланган Кече эшмәкәрлек субъектларын үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган «Агропрогресс» грантларын бирү тәртибендә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Бу Тәртип Татарстан Республикасының авыл территорияләрендә яки авыл агломерацияләре территорияләрендә «Агропрогресс» проектын тормышка ашыру максатларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасы турында» 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары белән расланган Авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасында каралган дәүләт ярдәменең башка юнәлешләре кысаларында капланмый торган чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә микропредприятие субъекты яки кече предприятие критерийларына җавап бирүче, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән, Татарстан Республикасы авыл территориясендә яки авыл агломерациясе территориясендә эшчәнлек алып баручы, теркәлгән датадан 24 айдан артык эшчәнлек башкаручы авыл хуҗалыгы товары җитештерүчеләренә (крестьян (фермер) хуҗалыкларыннан, шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан, крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыклары

булган индивидуаль эшмәкәрләрдән һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган «Агропрогресс» грантларын (алга таба шул ук эзлеклелектә – Дәүләт программасы, грант, заявка бирүче) бирү максатларын, тәртибен һәм шартларын билгели.

Грант йөзем бакчасын утырту һәм (яки) карау чыгымнарының бер өлешен финанслар белән тәэмин итүгә бирелми.

Грант бирү шарты – заявка бирүченең үз эшчәнлеген гамәлгә ашырырга һәм грант алынган көннән 7 ел дәвамында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) «Агропрогресс» проектын тормышка ашыру турында хисап бирергә бурычлы булуы.»;

1.3 пунктта «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык)» сүзләрен «Министрлыкка» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта:

«г» һәм «д» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бирергә:

«г) «Агропрогресс» проекты – конкурс комиссиясенә Министрлык тарафыннан билгеләнгән форма буенча һәм тәртиптә тапшырыла торган, Министрлык һәм кредит оешмасы белән килештерелгән грант чыгымнарының исемлеген үз эченә алган, «Агропрогресс» проектын тормышка ашыруга җәлеп ителә торган инвестиция кредиты акчасын алу планлаштырыла торган документ (бизнес-план). «Агропрогресс» проекты кысаларында сатып алына торган мөлкәт һәм башкарыла торган эшләр исемлеге, шулай ук чыгымнар исемлеген килештерү процедурасы Министрлык тарафыннан билгеләнә. Грант алучы грантны сарыф итү операцияләрен Министрлыкның ризалыгы белән генә үткәрергә хокуклы;

д) эшчәнлекнең план күрсәткечләре – «Агропрогресс» проектына кертелә торган җитештерү һәм икътисадый күрсәткечләр, шул исәптән Россия Федерациясе Пенсия фондына хисап бирелә торган яңа даими эш урыннары һәм хезмәткәрләр саны, эш урыннары булдырылган датадан кимендә биш ел дәвамында булдырылган эш урыннарын саклау, натураль һәм акчалата күрсәткечләрдә чагылдырылган авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү һәм аны реализацияләү күләме;»;

«ж» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ж) «Агропрогресс» гранты – конкурс комиссиясе карары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан заявка бирүчеләргә күчерелә торган бюджет ассигнованиеләре;»;

2.1 пунктта:

«а» пунктчасында «120» саннарын «200» саннарына алмаштырырга;

«в» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

«д» пунктчасында «Агропрогресс» гранты акчасы белән тормышка ашырыла торган грант алучы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Грант алучы тарафыннан грант түбәндәгеләргә сарыф ителергә мөмкин:

а) авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү, аларны саклау, эшкәртү һәм реализацияләү өчен билгеләнгән объектларны сатып алуга, төзүгә һәм модернизацияләүгә, әлеге объектларны техника, транспорт һәм җиһаз белән комплектлауга, авыл хуҗалыгы хайваннары (дуңгыздан башка) һәм кош-кортлар сатып алуга;

б) грант алынган көннән иң күбе 18 ай дәвамында «Агропрогресс» проектын тормышка ашыруга җәлеп ителгән кредит буенча процентлар түләүгә.

Мөгезле эре терлекне үстерүгә юнәлдерелгән «Агропрогресс» проектында каралган мөгезле эре терлекнең планлаштырыла торган ана баш саны 400 баштан артмаска тиеш.

Грант акчасы грант алынганга кадәр тормышка ашырыла башланган (грант акчасы элек тормышка ашырыла башланган проект кысаларында финанслана торган чыгымнарны кабатламау шарты белән проект агымдагы финанс елында тормышка ашырыла башланган очрактан тыш) агросәнәгать комплексы өлкәсендәге проектларны тәмамлауга сарыф ителә алмый.

2.4 пунктның уникенче абзацында татар текстында «килешүгә» сүзен «грант бирү турында килешүгә (алга таба – килешү)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктта:

«д» пунктчасында татар текстында «проектны» сүзен «Агропрогресс» проектын» сүзләренә алмаштырырга;

«е» пунктчасының бишенче абзацында «грант алу өчен» сүзләрен төшереп калдырырга;

«н» пунктчасында «әлеге проектта» сүзләрен «Агропрогресс» проектында» сүзләренә алмаштырырга;

2.8 пунктның өченче абзацында «проект» сүзен «Агропрогресс» проекты» сүзләренә алмаштырырга;

2.9 пунктның унҗиденче абзацында «заявка бирүче» сүзләрен «Агропрогресс» сүзенә алмаштырырга;

2.10 пунктның егерме дүртенче абзацында татар текстында «проектны» сүзен «Агропрогресс» проектын» сүзләренә алмаштырырга;

2.11 пунктта:

икенче абзацта «сайлап алуда катнашучыларның микъдари составы буенча кирәкле грантлар саны» сүзләрен «кирәкле финанслау лимиты» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әгәр сайлап алуда катнашу өчен бер заявка да бирелмәгән булса, конкурс комиссиясе беркетмәдә бирелгән заявкалар булмау фактын чагылдыра.

Әгәр сайлап алуда барлык катнашучыларның заявкалары кабул ителмәгән булса, конкурс комиссиясе беркетмәдә заявкалар кабул ителмәү фактын чагылдыра.

Әгәр, бер заявкадан башка, сайлап алуда барлык катнашучыларның заявкалары кабул ителмәгән булса, конкурс комиссиясе беркетмәдә сайлап алуда бердәнбер җиңүчене тану фактын чагылдыра.»;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. «Агропрогресс» грантын файдалану срогы алынган көннән иң күбе 24 ай тәшкил итә. Аннан файдалану Министрлык карары белән Министрлык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, әмма иң күбе алты айга озайтылырга мөмкин. Грант алучының грант акчасын билгеләнгән срокта файдалануга комачаулый һәм каршы торып бетерә алмый торган шартлар башлануны документлар белән раславы Министрлык тарафыннан гранттан файдалану срогын озайту турында карар кабул ителү өчен нигез булып тора.

2021 – 2022 елларда грант алучыларга бирелгән гранттан файдалану срогын

озайту Министрлык карары буенча Министрлык тарафыннан билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә, әмма иң күбе 12 айга рөхсәт ителә. Шул ук вакытта гранттан файдалану срогын озайту әлеге грант алучыларның Министрлыкка гранттан файдалану срогы тәмамланганга кадәр 15 календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрелгән гаризасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Грантның максималь күләме бер заявка бирүчегә 30,0 млн.сум күләмендә, әмма «Агропрогресс» проекты кыйммәтенең иң күбе 25 процентын тәшкил итә.

«Агропрогресс» проекты кыйммәтенең кимендә 70 проценты әлеге «Агропрогресс» проектын тормышка ашыруга җәлеп ителә торган инвестиция кредиты акчасы белән тәэмин ителергә тиеш, «Агропрогресс» проекты кыйммәтенең иң күбе 25 проценты – грант акчасы белән, «Агропрогресс» проекты кыйммәтенең кимендә 5 проценты грант алучының үз акчасы белән тәэмин ителә.

Салым түләүченең өстәлгән кыйммәткә салым исәпләүгә һәм түләүгә бәйле йөкләмәләрен үтәүдән азат итү хокукыннан файдаланучы грант алучылар өчен чыгымнарның бер өлешен финанслар белән тәэмин итү бу Тәртипнең 2.2 пунктында күрсәтелгән товар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу чыгымнары суммасыннан (өстәлгән кыйммәткә салым суммасын кертеп) чыгып гамәлгә ашырыла.

Элек грант алынган «Агропрогресс» проектын тормышка ашырып бетерү, элек грант акчасы белән тормышка ашырылган «Агропрогресс» проекты эшчәнлегенең план күрсәткечләренә үзгәрешләр кертелмәү шарты белән яисә каршы торып бетерә алмый торган шартлар башлану аркасында элек грант акчасы белән тормышка ашырылган «Агропрогресс» проекты эшчәнлегенең план күрсәткечләренә иң күбе 10 процентка үзгәрешләр кертү шарты белән грант алырга мөмкин.

Грант алучылар элек тормышка ашырылган «Агропрогресс» проекты эшчәнлегенең план күрсәткечләренә тулы күләмдә ирешү шарты белән яңадан, әмма элек грант алынган датадан кимендә 36 ай узгач грант алырга мөмкин.

3.2 пунктта:

дүртенче абзацта татар текстында «проектның» сүзен «Агропрогресс» проектының» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта татар текстында «проектны» сүзен «Агропрогресс» проектын» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «3.2» саннарын «3.1» саннарына алмаштырырга;

3.3 пунктның унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) килешү төзүдән тыелып калганда, конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс комиссиясе утырышының беркетмәсенә, әлеге күрсәтеп үтелгән сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) төшереп калдырып һәм иң күп балл җыйган, финанслау лимиты булмау аркасында кабул ителми калган чираттагы заявка бирүчене җиңүче дип танып, үзгәрешләр кертелә.»;

әлеге карар белән расланган Гаилә фермаларын үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган грантлар бирү тәртибендә:

1.1 пунктта татар текстында «үстерүгә» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләрен өстәргә, «авыл хуҗалыгы товары житештерүче крестьян (фермер) хуҗалыкларына яки индивидуаль эшмәкәрләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә» сүзләрен төшереп калдырырга,

«грант алучы» сүзләрен «Дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта:

«а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) гаилә фермасы – крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы гаиләсенең ике (башлыкны кертеп) һәм аннан да күбрәк әгъзасыннан (туганлык һәм (яки) үги туганлык белән берләштерелгән) торган крестьян (фермер) хуҗалыгы яки Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан Татарстан Республикасының авыл территориясендә яки авыл агломерациясе территориясендә теркәлгән, теркәлү датасыннан 12 айдан артыграк эшчәнлек гамәлгә ашырган, Татарстан Республикасының авыл территориясендә яки авыл агломерациясе территориясендә эшчәнлек гамәлгә ашырган, составына индивидуаль эшмәкәр гаиләсенең ике һәм аннан да күбрәк әгъзасы (туганлык һәм (яки) үги туганлык белән берләштерелгән) кергән крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы булучы индивидуаль эшмәкәр;»;

«в» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Грант алучы проектын тулы күләмдә тормышка ашырган һәм эшчәнлекнең план күрсәткечләренә ирешкән грант алучылар моңа кадәр грант алган датадан кимендә 36 айдан соң гаилә фермасын үстерүгә грант алырга мөмкин.»;

түбәндәге эчтәлекле «з» пунктчасын өстәргә:

«з) грант алучы проекты – конкурс комиссиясенә Министрлык тарафыннан билгеләнгән форма буенча һәм тәртиптә тапшырыла торган, гаилә фермасын үстерүгә гранттан файдалану шартлары һәм чыгымнар юнәлешләре, шулай ук грант бирү турындагы килешүдә (алга таба – килешү) үтәү йөкләмәсе билгеләнә торган эшчәнлекнең план күрсәткечләре кертелә торган документ (бизнес-план). Грант алучы проекты Министрлыкка Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә электрон рәвештә җибәрелергә мөмкин.»;

2.1 пунктта:

«г» пунктчасында «хуҗалык башлыгы һәм аның әгъзалары яңа гына эшли башлаган фермерлар өчен грантлар һәм гаилә фермаларын үстерү өчен грант алучы булмаган яисә гаилә фермаларын үстерү өчен грант, яңа гына эшли башлаган фермерлар өчен грант һәм «Агростартап» проектлары буенча грант тулысынча үзләштерелгән датадан кимендә 18 ай узган» сүзләрен «Дәүләт программасы нигезендә «Агростартап» гранты, яңа гына эшли башлаган фермерга ярдәм күрсәтү өчен грант, гаилә терлекчелек фермаларын һәм гаилә фермаларын үстерү өчен грант алган, грант алучы проектын тулы күләмдә тормышка ашырган һәм эшчәнлекнең план күрсәткечләренә ирешкән грант алучылар, моңа кадәр грант алган датадан кимендә 36 ай узгач, гаилә фермасын үстерү өчен грант алырга мөмкин» сүзләренә алмаштырырга, татар текстында «проектларга» сүзен «грант алучылар проектларына» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле «н» пунктчасын өстәргә:

«н) заявка бирүче үз-үзен җайга сала торган оешмага керергә рөхсәте булган оешма тарафыннан төзелеш контролен гамәлгә ашыруны һәм бу эшне башкаручы белгечләр Төзелеш өлкәсендәге белгечләрнең илкүләм реестрына кертелү шарты белән (грант авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү, саклау һәм эшкәртү объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга яки модернизацияләүгә файдаланылганда) оештыра.»;

2.4 пунктның уникенче абзацында «грант бирү турында», «(алга таба – килешү)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.6 пунктта:

«г» пунктчасында «1-эшмәкәр», «һәм (яки) «Сәнәгать максатында балык үрчетү (аквакультура) продукциясен җитештерү (үстерү) турында мәгълүматлар» дигән ПР һәм (яки) «Сәнәгать максатында балык үрчетү (аквакультура) продукциясен реализацияләү турында мәгълүматлар» дигән РППР формалары буенча» сүзләрен «Товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр җитештерү һәм аларны төяп җибәрү турында мәгълүматлар» дигән П-1 һәм (яки) «Кече предприятие тарафыннан продукция җитештерү турында мәгълүматлар» дигән ПМ-пром» сүзләренә алмаштырырга;

«к» пунктчасында «рөхсәтнамә» сүзен «рөхсәтнамә күчермәсе» сүзләренә алмаштырырга;

«р» һәм «с» пунктчалары үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле «ч» пунктчасын өстәргә:

«ч) төзелеш контроле шартнамәсе (грант авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү, аларны саклау һәм эшкәртү объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә, капиталь ремонтлауга яки модернизацияләүгә файдаланылганда).»;

2.11 пунктның икенче абзацында «сайлап алуда катнашучыларның микъдари составы буенча грантлар саны» сүзләрен «финанслау лимиты» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Әгәр сайлап алуда катнашу өчен бер заявка да бирелмәгән булса, конкурс комиссиясе беркетмәдә бирелгән заявкалар булмау фактын чагылдыра.

Әгәр сайлап алуда барлык катнашучыларның заявкалары кабул ителмәгән булса, конкурс комиссиясе беркетмәдә заявкалар кабул ителмәү фактын чагылдыра.

Әгәр, бер заявкадан башка, сайлап алуда барлык катнашучыларның заявкалары кабул ителмәгән булса, конкурс комиссиясе беркетмәдә сайлап алуда бердәнбер җиңүчене тану фактын чагылдыра.»;

3.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Грант алучының элек грант алынган проектын тормышка ашырып бетерү, грант алучының элек грант акчасы белән тормышка ашырылган проекты эшчәнлегенең план күрсәткечләренә үзгәрешләр кертелмәү шарты белән, яисә каршы торып бетерә алмый торган шартлар башлану аркасында грант алучының элек грант акчасы белән тормышка ашырылган проекты эшчәнлегенең план күрсәткечләренә иң күбе 10 процентка үзгәрешләр кертү шарты белән грант алырга мөмкин.

2021 – 2022 елларда грант алучыга бирелгән гранттан файдалану срогын озайту Министрлык карары буенча Министрлык тарафыннан билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә, әмма иң күбе 12 айга рөхсәт ителә. Шул ук вакытта гранттан файдалану срогын озайту әлеге грант алучыларның Министрлыкка гранттан файдалану срогы тәмамлануга кадәр 15 календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрелгән гаризасы нигезендә гамәлгә ашырыла. Әгәр 2021 – 2022 елларда грант алучылар тарафыннан грант алучы проектында каралган эшчәнлекнең 2022 елда үтәлү срогы җиткән план күрсәткечләренә ирешү буенча йөкләмәләр бозылган булса, әлеге йөкләмәләр бозылган өчен җаваплылык чаралары Министрлык карары буенча аның тарафыннан

билгеләнгән тәртиптә кулланыла.

Грант алучы үз эшчәнлеген гамәлгә ашырырга һәм грант алынган көннән 7 ел эчендә Министрлыкка грант алучы проектын тормышка ашыру турында хисаплылык бирергә бурычлы.

Грант акчасы йөзем бакчасын утырту һәм (яки) карау чыгымнарының бер өлешен финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) бирелми.»;

3.3 пунктның дүртенче абзацында татар текстында «проектта» сүзен «грант алучы проектында» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) килешү төзүдән тыелып калганда, конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә әлеге күрсәтеп үтелгән сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) төшереп калдыру һәм иң күп балл җыйган, финанслау лимиты булмау аркасында кабул ителми калган чираттагы заявка бирүчене җиңүче дип тану турында үзгәрешләр кертелә»;

4.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әгәр каршы торып бетерә алмый торган шартлар башлану аркасында грант алучылар тарафыннан грант бирү нәтиҗәсенә ирешү йөкләмәләре бозылган булса, Министрлык карарында бу Тәртипнең 3.2 пункты нигезендә гранттан файдалану срокларын озайту яисә, конкурс комиссиясе белән килештереп, грант бирү нәтиҗәсе күрсәткечен киметү карала.»;

әлеге карар белән расланган Авыл хуҗалыгы куллanучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджеттан финанслаша торган грантлар бирү тәртибендә:

1.1 пунктта:

«грант алучы» сүзләреннән соң «Дәүләт программасы» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Грант акчасы йөзем бакчасын утырту һәм (яки) карау чыгымнарының бер өлешен финанслар белән тәэмин итүгә бирелми.»;

1.2 пунктта:

өченче абзацта татар текстында «эшкәртү һәм (яки) сату эшчәнлеген» сүзләре алдына «әлеге продукцияне» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта татар текстында «кара-каршы әңгәмә яки видеоконференция элемтәсе формасында грант алучылар» сүзләрен «яшелчәчелек, бәрәңге үстерү, сөт һәм ит терлекчелеген үстерү проектларын карап тикшерү өстенлеген исәпкә алып, кара-каршы әңгәмә яки видеоконференция элемтәсе формасында грант алучылар, шулай ук Дәүләт программасы кысаларында элек грант алмаган авыл хуҗалыгы товары җитештерүчеләр» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «грант алучы проектына» сүзләрен «проектка» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«грант алучы проекты – конкурс комиссиясенә Министрлык тарафыннан билгеләнгән форма буенча һәм тәртиптә тапшырыла торган, матди-техник базаны үстерүгә гранттан файдалану шартлары һәм чыгымнар юнәлешләре, шулай ук грант бирү турындагы килешүдә (алга таба – килешү) үтәү йөкләмәсе билгеләнә торган эшчәнлекнең план күрсәткечләре кертелә торган документ (бизнес-план). Грант

алучы проекты Министрлыкка Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә электрон рәвештә җибәрелергә мөмкин.»;

1.5 пунктның алтынчы абзацында татар текстында «грант алучы проектын» сүзләрен «проектны» сүзенә алмаштырырга;

3.1 пунктның уникенче абзацында «грант бирү турында», «(алга таба – килешү)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.2 пунктның бишенче абзацында татар текстында «проектның» сүзен «заявка бирүче проектының» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) грант алучының элек грант алынган проектын тормышка ашырып бетерү, грант алучының элек грант акчасы белән тормышка ашырылган проекты эшчәнлегенең план күрсәткечләренә үзгәрешләр кертелмәү шарты белән, яисә каршы торып бетерә алмый торган шартлар башлану аркасында грант алучының элек грант акчасы белән тормышка ашырылган проекты эшчәнлегенең план күрсәткечләренә иң күбе 10 процентка үзгәрешләр кертү шарты белән матди-техник базаны үстерүгә грант алырга мөмкин.

Грант алучылар элек тормышка ашырылган проект эшчәнлегенең план күрсәткечләренә тулы күләмдә ирешү шарты белән яңадан, әмма элек грант алган датадан кимендә 36 айдан соң грант алырга мөмкин;»;

5.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Җиңүче (җиңүчеләр) килешү төзүдән тыелып калганда, конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә, әлеге сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) төшереп калдырып, үзгәрешләр кертелә.

Әгәр сайлап алуда катнашу өчен бер заявка да бирелмәгән булса, конкурс комиссиясе беркетмәдә бирелгән заявкалар булмау фактын чагылдыра.

Әгәр сайлап алуда барлык катнашучыларның заявкалары кабул ителмәгән булса, конкурс комиссиясе беркетмәдә заявкалар кабул ителмәү фактын чагылдыра.

Әгәр, бер заявкадан башка, сайлап алуда барлык катнашучыларның заявкалары кабул ителмәгән булса, конкурс комиссиясе беркетмәдә сайлап алуда бердәнбер җиңүчене тану фактын чагылдыра.»;

5.12 пунктның унөченче абзацында татар текстында «проектны» сүзен «заявка бирүче проектын» сүзенә алмаштырырга;

5.14 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әгәр каршы торып бетерә алмый торган шартлар аркасында грант алучылар тарафыннан грант бирү нәтиҗәсенә ирешү йөкләмәләре бозылган булса, Министрлык карарында бу пунктның икенче абзацында билгеләнгән тәртиптә нәтиҗәгә ирешү срокларын озайту яисә, конкурс комиссиясе белән килештереп, нәтиҗә күрсәткечен киметү карала.»;

6.1 пунктта:

беренче абзацта татар текстында «проектны» сүзен «грант алучы проектын» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта татар текстында «проектның» сүзен «грант алучы проектының» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта татар текстында «проектны» сүзен «грант алучы проектын» сүзләренә алмаштырырга;

7.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2021 – 2022 елларда грант алучыларга бирелгән гранттан файдалану срогын озайту Министрлык карары буенча Министрлык тарафыннан билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә, әмма иң күбе 12 айга рөхсәт ителә. Шул ук вакытта гранттан файдалану срогын озайту әлеге грант алучыларның Министрлыкка гранттан файдалану срогы тәмамлануга кадәр 15 календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрелгән гаризасы нигезендә гамәлгә ашырыла. Әгәр 2021 – 2022 елларда грант алучылар тарафыннан грант алучы проектында каралган эшчәнлекнең 2022 елда үтәлү срогы җиткән план күрсәткечләренә ирешү буенча йөкләмәләр бозылган булса, әлеге йөкләмәләр бозылган өчен җаваплылык чаралары Министрлык карары буенча аның тарафыннан билгеләнгән тәртиптә кулланыла.»;

әлеге карар белән расланган Хуҗалыклар төзү һәм (яки) аларны үстерү проектларын тормышка ашыруга бәйле булган, федераль бюджеттан финанслаша торган «Агростартап» грантларын Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү тәртибендә:

1.5 пунктта:

«а» пунктчасында «заявка бирүчегә» сүзләрен «грант алучыга» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«в) авыл агломерацияләре – бер-берсенә тоташкан авыл территорияләре һәм (яки) авыл территорияләре белән янәшә булган шәһәр тибындагы поселоклар һәм (яки) кече шәһәрләр. Авыл агломерациясе составына керә торган һәр торак пункт территориясендә даими яшәүче халык саны 30 мең кешедән арта алмый. Бер-берсенә тоташкан авыл территорияләре дигәндә муниципаль берәмлекләрнең чиктәш чикләренә ия авыл территорияләре аңлашыла. Авыл агломерацияләре исемлеге Министрлыкның «Татарстан Республикасының авыл территорияләре исемлеген һәм Татарстан Республикасының авыл агломерацияләре исемлеген раслау турында» 2020 елның 5 мартындагы 48/2-пр номерлы боерыгы белән расланган;»;

«г» пунктчасында «әгъзалары булган крестьян (фермер) хуҗалыгына яки индивидуаль эшмәкәргә» сүзләрен «әгъзасы булган грант алучыга» сүзләренә алмаштырырга;

«д» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) заявка бирүче – авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү һәм (яки) аларны эшкәртү төп эшчәнлек төрләре булып торган крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (алга таба – КФХ) булган, агымдагы финанс елында Татарстан Республикасының авыл территориясендә яки авыл агломерациясе территориясендә теркәлгән, акча алынган көннән кимендә 5 ел дәвамында авыл территориясендә яки авыл агломерациясе территориясендә эшчәнлек алып барырга һәм хуҗалык төзү һәм (яки) аны үстерү проектында каралган эшчәнлек күрсәткечләренә ирешергә бурычлы булган, финанс ярдәме акчасын (эшмәкәрлек эшчәнлегенең башлангыч этабын оештыруга социаль түләүләрдән һәм түләүләрдән, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасы турында» 2012 елның 14 июлендәге 717 номерлы карары белән расланган Авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу буенча дәүләт программасына 8 нче кушымта нигезендә шәхси ярдәмче хуҗалыклар алып баручы гражданнарга бирелә торган субсидияләрдән тыш), субсидияләр яки грантлар, шулай ук әлеге

Дәүләт программасы кысаларында яңа гына эшли башлаган фермерга ярдәм күрсәтүгә грант алучы яки моңа кадәр грант алучы булмаган крестьян (фермер) хуҗалыгы яки индивидуаль эшмәкәр.

«Заявка бирүче» төшенчәсенә шулай ук Министрлыкның грант бирү турында карары кабул ителгән датадан 30 календарь көннән артмаган срокта бу пунктның «д» пунктчасында каралган шартларга туры килә торган крестьян (фермер) хуҗалыгын Федераль салым хезмәте органнарында дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашырырга яки индивидуаль эшмәкәр буларак теркәлергә бурычлы Россия Федерациясе гражданы керә;»;

«е» пунктчасында татар текстында «грант бирү өчен» сүзләреннән соң «, яшелчәчелек, бәрәңге үстерү, шулай ук сөт терлекчелеген үстерү хуҗалыгын булдыру (яки) үстерү проектларын карап тикшерү (шул исәптән кара-каршы әңгәмә һәм (яки) видеоконференция элемтәсе формасында) өстенлеген исәпкә алып,» сүзләрен өстәргә;

«з» пунктчасында «заявка бирүче» сүзләрен «грант алучы» сүзләренә алмаштырырга;

«л» һәм «м» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бирергә:

«л) «шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы граждан» – «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып баруны гамәлгә ашыручы граждан;

м) грант алучы – грант бирү өчен конкурс комиссиясе тарафыннан сайлап алынган, «Юридик затларны һәм индивидуаль эшмәкәрләрне дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә крестьян (фермер) хуҗалыгы яки индивидуаль эшмәкәр буларак теркәлгән заявка бирүче;»;

түбәндәге эчтәлекле «н» пунктчасын өстәргә:

«н) эшкәртүче – «Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 елның 29 декабрендәге 264-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 1 өлеше һәм (яки) 7 статьясындагы 1 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган исемлекләргә таянып, авыл хуҗалыгы продукциясен саклауны, беренчел һәм (яки) шуннан соңгы (сәнәгать максатында) эшкәртүне (шул исәптән арендага алынган төп чараларда) гамәлгә ашыручы авыл хуҗалыгы товары җитештерүче (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативыннан тыш).»;

3.1 пунктта:

беренче абзацта «заявка бирүчегә» сүзләрен «грант алучыга» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасында «Грант күләме Министрлык тарафыннан билгеләнә» сүзләрен – «Билгеле бер грант алучыга бирелә торган грант күләме конкурс комиссиясе карары белән билгеләнә» сүзләренә, «заявка бирүченең» сүзләрен «крестьян (фермер) хуҗалыгы төзү һәм (яки) аны үстерү проектын тормышка ашыруга җибәрелә торган грант алучының» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчасында «заявка бирүче» сүзләрен «грант алучы» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктның «е» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Грант алучының бу Тәртипнең 3.2 пунктындагы «е» пунктчасы нигезендә билгеләнгән срокта грант акчасын файдалануга комачаулый һәм каршы торып бетерә алмый торган шартлар башлануын документлар нигезендә раславы Министрлык тарафыннан гранттан файдалану срогын озайту турында карар кабул итү өчен нигез булып тора.

2021 – 2022 елларда грант алучыларга бирелгән гранттан файдалану срогын озайту Министрлык карары буенча Министрлык тарафыннан билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә, әмма иң күбе 12 айга рөхсәт ителә. Шул ук вакытта гранттан файдалану срогын озайту грант алучының Министрлыкка гранттан файдалану срогы тәмамлануга кадәр 15 календарь көннән дә соңга калмыйча җибәрелгән гаризасы нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3.3 пунктның икенче абзацында «60» саннарын «45» саннарына алмаштырырга;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Грантлар терлекчелек һәм үсемлекчелек продукциясен җитештерү күләме һәм баш саны буенча түбәндәге проектлана торган куәт шарты белән бирелә:

сөт фермалары кимендә 40 баш сыер (1 елга кимендә 180 тонна сөт җитештерү);

симертү өчен мөгезле эре терлек ашату фермалары кимендә 80 баш (1 елга тереләй авырлыкта кимендә 19 тонна ит);

сарык үрчетү фермалары кимендә 300 баш сарык, шул исәптән кимендә 100 ана сарык (1 елга тереләй авырлыкта кимендә 8 тонна ит җитештерү);

савым кәҗәләре – кимендә 80 баш (1 елга кимендә 60 тонна сөт җитештерү);

ит җитештерелә торган кошчылык фермалары – тереләй авырлыкта ит җитештерү буенча түбәндәге бер еллык әйләнеш һәм баш саны белән:

йомырка җитештерелә торган кошчылык фермалары – түбәндәге күләмдә бер елга йомырка җитештерү һәм баш саны белән:

10 мең баш йомырка сала торган тавык (кимендә 2,6 млн.данә йомырка);

20 мең баш бытбылдык (кимендә 5 млн.данә йомырка);

яшь терлек үстерү буенча кошчылык фермасы – тереләй масса артымының түбәндәге бер еллык әйләнеше һәм баш саны белән:

кимендә 10 мең баш бройлер (кимендә өч тонна);

ат фермалары кимендә 80 ат, шул исәптән кимендә 32 ана ат (бер елга тереләй авырлыкта кимендә 5 тонна ит җитештерү);

сату өчен билгеләнгән балык җитештерү (үстерү) фермалары 1 елга кимендә биш тонна;

бәрәңге үстерү кимендә 20 гектар чәчү мәйданы;

ачык грунт яшелчәчелеге кимендә 10 гектар чәчү мәйданы;

ябык грунт яшелчәчелеге кимендә 2 000 мең кв.метр чәчү мәйданы;

бөртекле һәм кузаклы ашлык җитештерү кимендә 200 гектар чәчү мәйданы;

азык культуралары кимендә 150 гектар чәчү мәйданы;

техник культуралар кимендә 150 гектар чәчү мәйданы;

җиләк культуралары үстерү 2,6 гектар утырту мәйданы;

җимеш культуралары үстерү (интенсив бакчалар) кимендә 5,0 гектар утырту мәйданы;

куян асрау – кимендә 12 мең куян, шул исәптән кимендә 2 000 ана куян (бер елга кимендә 20 тонна ит һәм кимендә 8 мең тире җитештерү);

гөмбә үстерү – кимендә 2 000 мең кв.метр чәчү мәйданы.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.10 пункт өстәргә:

«4.10. Әгәр сайлап алуда катнашу өчен бер заявка да бирелмәгән булса, конкурс комиссиясе беркетмәдә бирелгән заявкалар булмау фактын чагылдыра.

Әгәр сайлап алуда барлык катнашучыларның заявкалары кабул ителмәгән булса, конкурс комиссиясе беркетмәдә заявкалар кабул ителмәү фактын чагылдыра.

Әгәр, бер заявкадан башка, сайлап алуда барлык катнашучыларның заявкалары кабул ителмәгән булса, конкурс комиссиясе беркетмәдә сайлап алуда бердәнбер җиңүчене тану фактын чагылдыра.

Җиңүче (җиңүчеләр) килешү төзүдән тыелып калганда, конкурс комиссиясе тарафыннан конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә, әлеге сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) төшереп калдырып, үзгәрешләр кертелә.»;

5.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12. Баллары тигез берничә заявка бирүчеләр булганда, кирәкле финанслау лимиты фактта булмаганда, грант заявкаларны теркәү журналында заявкасының теркәлү срогы иң алдан булган заявка бирүчегә бирелә.»;

6.1 пунктта:

икенче абзацта «3,0» саннарын «5,0» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «4,0» саннарын «6,0» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «1,5» саннарын «3,0» саннарына алмаштырырга;

бишенче абзацта «2,0» саннарын «4,0» саннарына алмаштырырга;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгәр каршы торып бетерә алмый торган шартлар аркасында грант алучылар тарафыннан грант бирү нәтиҗәләренә ирешү йөкләмәләре бозылган булса, Министрлык карарында бу Тәртипнең 3.2 пунктындагы «е» пунктчасы нигезендә гранттан файдалану срокларын озайту яисә, конкурс комиссиясе белән килештереп, нәтиҗәләр күрсәткечен кимету карала.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин